# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

"Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында" 2001 елның 24 гыйнварындагы 595 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 1-2; 2005, № 1 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның алтынчы абзацында "табигать" сүзен төшереп калдырырга;

2) 4 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын торгызуны тәэмин итүче, шулай ук мондый эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмаучы яисә чикләүче алымнар белән авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүне гамәлгә ашырырга;";

3) 10 статьяның икенче өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

4) 16 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"16 статья. **Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләренең туфрагын, агрохимикатларны һәм пестицидларны сертификацияләү һәм аларның тәңгәллеген декларацияләү**

Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләре туфрагы, агрохимикатлар һәм пестицидлар техник җайга салу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри сертификацияләнергә яисә аларның тәңгәллеге декларацияләнергә тиеш.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 16 мае
№ 21-ТРЗ